**МАОУ СОШ № 1 Нурлат шәһәре**
**Татарстан Республикасы**

# IX ачык региональ интернет – конкурс «Җиңәргә өйрән» «Районымның атаклы урыннары»



**Презентацияне әзерләделәр:**
**Шагиев Денис – 9 сыйныф укучысы**
**Аглиуллина Диләрә – 11 сыйныф укучысы.**

**Җитәкчеләре:**
**Сафина Х.Г.**
**Набиуллина Ф.М.**
**Усманова Ф.И.**

# *Максат:*

*1*. Нурлат районы белән таныштыру.
2.Нурлат һәм аның тарихын пропагандалау.
3.Туристларда Нурлат җирлеге тарихы һәм шушы җирлектән чыккан күренекле шәхесләрнең
тарихта калдырган эзе турында кызыксыну уяту.



# *Бурычлар:*

Нурлат турында түбәндәге юнәлешләрдә мәгълүмат бирергә:

1. Географик урыны.
2. Тарихы.
3. Күренекле шәхесләр.

# *Нурлат*

*Нурлат районы республиканың көньягына урнашкан. Район аша Олы Чирмешән, Кондырча. Сөлчә елгалары ага. Казан-Нурлат арасы 220 км. Районыбызда кара туфраклы җир. Туган ягыбыз кара алтын ятмаларына бай. Районыбызда төрле милләт халыклары дус һәм тату яшиләр. Татарлар-52%, чувашлар -27%, руслар -19%, башка милләт вәкилләре -2%.*

**Үзәге: Нурлат шәһәре**

**Территориясе: 2308,95 кв. км**

**Халкы: 59,5 мең кеше**



# Экскурсияне түбәндәге маршрут буенча үткәрәбез:

1.Күренекле шәхес, артист, режиссер, җәмәгать эшлеклесе, татар театрына нигез салучы -Г.Кариевның туган ягы-Колбай Мораса авылы музее.

2.Күпьеллык тарихлы, бик күп күренекле шәхесләргә белем учагы булган Кизләү авылы мәдрәсәсенә һәм музее.

3.Күренекле рәссам, шагыйрь Г.Сәгыйрев музее.

4.Нурлат шәһәрендә урнашкан Кама аръягы музее .

.



# Г.Кариев музее




Татар театрына нигез салучы кеше  Г. Кариевның безнең якташыбыз булуы үзе генә дә нинди горурлык!

Г. Кариев – күренекле татар артисты, педагог, җәмәгать эшлеклесе, драматург . Г.Кариевның исеме мәңгеләштерелде. Казан татар дәүләт яшь тамашачылар театрына ,профессиональ татар театр сәнгатенә нигез салучы, режиссер, артист  Г. Кариев исеме бирелде. Колбай Мораса авылында Г. Кариев музее ачылды. Ул 1986 елда төзелде,  ә 1992 елдан Татарстан Милли музееның филиалы буларак яши башлады.

Колбай Мораса авылында Г. Кариев музее ачылды. Ул 1986 елда төзелде, ә 1992 елдан Татарстан Милли музеенең филиалы буларак яши башлады.

Бүгенге көндә музейда 4 зал эшли:

1.Габдулла Кариев истәлекләре залы

2.Колбай Мораса авылы тарихы залы

3.Сугыш һәм хезмәт даны залы

4.Театрлар тарихы залы.





# Кизләү



Кизләү авылы музее 1980 нче елда ачылган. Ул Кизләү авылы мәктәбе бинасында урнашкан.

Музейның төп максаты: укучыларда туган илгә һәм аның үткән тарихына кызыксыну һәм мәхәббәт хисләре формалаштыру.

**Музей экспозиция, экскурсия, фәнни-тикшеренү юнәлешләрендә эш алып бара. Бүгенге көндә музейда 382 экспонат бар. Алар халык көнкүреше предметлары, Бөек Ватан сугышы каһарманнары турында мәгълүмат, күмәк хуҗалык тарихы, авылның күренекле шәхесләре турында мәгълүмат,  меңеллык тарихлы мәдрәсәсе тарихы, тарихи казылмаларны бергә туплаган. Музейда тупланган материаллар безгә авылның күпьеллык тарихы, авыл мәдрәсәсендә белем алган бөек шәхесләр, XVII-XX гасырларда авыл халкының көнкүреше, сугыш**





# Г.Сагиров музее





Биккол авылында Г.Сагыйров музеена 2000 нче елда нигез салынган. Гакыйль ага бу мәктәптә 1,5 ел белем алган булган. Бүген Гакыйль абый бу дөньяда юк инде.

50 елдан артык урын өстендә хәрәкәтсез яткан Гакыйль абыйның батырлыгын искә төшереп торырлык әйберләр күп музейда. Ул аларны музейга үзе бүләк иткән. Биредә аның алты китабы, Язучылар берлеге әгъзасы булуын дәлилләүче документы, шәхси әйберләре, картиналарының күчермәләре саклана.

# Кама аръягы һәм Нурлат шәһәре төбәк тарихы музее



**2002 дә төбәк тарихы музее буларак ачыла, 2003 тән хәзерге исемдә. 2003–2005 тә ТР Милли музее филиалы , 2006елдан муниципаль музей.**

**Музей заллары:**

***«Нурлат тарихы»**
***«Авыл хуҗалыгы»**
***«Табигать»**
***«Археология һэм этнография»**
***« Нурлат районы спортчылары»**